**Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәпләрендәге**

**10 нчы сыйныф укучылары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан**

**IV Халыкара олимпиада биремнәре**

1. Г.Камалның “Банкрот” комедиясендә күтәрелгән проблемаларны һәм автор позициясен ачыклагыз, сез автор фикере белән килешәсезме? Үз фикерегезне дәлилләп языгыз (20 балл).
2. Г.Тукай иҗатына хас нинди сыйфатларны билгели аласыз? Аның шигырьләре бүгенге көндә дә актуальме, булса, кайсы яклардан дип уйлыйсыз? (20 балл)
3. *Яз язу, ләкин кызыкма һичвакыт шөһрәткә син; / Бик төренмә иртәгүк артык булыр чүпрәккә син* (Г.Тукай). Әлеге шигырь юлларына таянып, 150 сүздән дә ким булмаган күләмдә инша языгыз (20 балл).
4. Түбәндә тәкъдим ителгән аңлатмаларга нигезләнеп һәм җавап өлешендә күрсәтелгән сүзне истә тотып, туры килә торган фразеологик әйтелмәләрне языгыз. (**Һ**әр дөрес җавап - 2 балл; барлыгы 10 балл).

*1) нәрсәдәндер бик каты курку*

______________*курыккандай*________________________________

*2) күңелгә, искә алып кую*

*хәтергә* ___________________________________________________

*3) бик күптәнге, борынгы*

_________*бабадан*__________________________________________

*4) оста телле, уңган кеше турында*

_____________*кош*___________________________________________

*5) тәҗрибәле, дөнья күргән кеше турында*

____________*теше*__________________________________________

5. Түбәндә бирелгән сүзтезмәләрдәге бертөрле сүзләрне, мәгънәләренә карап, ике төркемгә аерыгыз. Омоним пар булган очракта янына омоним дип, күп мәгънәле сүзләр булганда, күп мәгънәле дип языгыз. (**Һ**әр дөрес җавап - 1 балл; барлыгы 5 балл).

*1) Сөйгән яр- утын яр* ____________

*2) Бур белән язу – бур эше* _______________

*3) чыршы энәсе – тегү энәсе*___________________

*4) Яшисе килә – яшь исе килә*____________________

*5) авыл башы – кеше башы*______________

6. Исемнең сан белән төрләнешенә аңлатма бирегез. Исемдәге күплек сан кушымчасының төрле мәгънәләр белдерә алуын мисаллар белән дәлилләгез. (10 балл)

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________
__________________________________________________________________________

7. Өзекне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез (Һәр бирем - 3 балл; барлыгы 15 балл).

*1) Томырылып чаба тулпарлар. 2) И ул атлар чапкандагы күңел бусагаларының дәртле ыргылып калулары! 3) Җир тетрәнә, җил үрсәләнә, җан алгысына.*

*4) Юртакларның борын канатлары чатнап киңәйгән, күзләрендә* **<...>** *кыргый ут. 5) Үз тыныннан кайнарланган һаваны гүя умырып тешләп, ярсу күкрәк белән алга ыргылалар. 6) Тояклары астыннан туфрак кантарлары түгел, ә очкыннар атылып кала сыман. 7) Әллә нинди дәһшәтле матурлык бу!*

*8) Дөньяны тетрәтеп ат йөрәге тибә... 9) Һавада – хәтер уянган җир исе, тиргә баткан тән исе, кытыкланган җил исе. 10) Өзәңгегә басып, җилгә каршы бөгелеп, тезгенне тоткан җайдак егетләр үзләре дә ат ялыннан яратылган шикелле; нинди генә гербөтен тәңгәллек! (М. Галиев)*

1. 7 нче җөмләдә <...> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз.

________________________________________________________________________

2. 5-7 нче җөмләләрдән сыйфаттан ясалган фигыльне язып алыгыз.

___________________________________________________________________________

3. Өзектән *ат* сүзенең синонимын табып язып алыгыз.

___________________________________________________________________________

4. Өзектәге кире сүз тәртибе кулланылган җөмләләрнең санын языгыз.

___________________________________________________________________________

5. Ирен гармониясе күзәтелгән сүзләре булган җөмләләрнең санын арта бару тәртибендә языгыз.

______________________________________________________________________